СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                        КАРАР

19.09.2017                                        38-152

с. Русское Макулово

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., 11 ст. Макыл авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Макыл авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2018нче елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларның түбәндәге эшләрне башкару буенча юлламасына рөхсәтегез бармы:

- Рус Макылы авылы Елга аръягы, Мәктәп, Мир урамнарында юлларга таш түшәү, Клянчино авылындагы зират коймаларын тотып алу, Исаево авылында һәм Сеитово авылында урамнарны яктырту фонарьлары сатып алу, 634500 сумлык.

ӘЙЕ                                        ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы                                        А. И. Матвеева